ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

02.12.2024 ел　　　　Баулы шәһәре　　　　№ 175

Территорияләрне планлаштыру проекты һәм ызанлау (межевание) проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кызылъяр авылы җирлеге чикләрендә урнашкан, «Туймазы нефть ятмасының 1202гс1 номерлы скважиналар кустын һәм Туймазы ятмасының 1202гс1 номерлы скважиналар кусты өчен линия коммуникацияләрен төзекләндерү» территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау (межевание) проекты (алга таба — проект) буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.
2. Проект буенча гавами тыңлаулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын 2024 елның 5 декабреннән 18 декабренә кадәр билгеләргә.

4. Гавами тыңлауларда каралачак Проект экспозициясен 2024 елның 5 декабрендә ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кызылъяр авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Баулы районы, Кызылъяр авылы, Тынычлык урамы, 9 йорт адресы буенча;

- Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кызылъяр авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында экспозицияне барып карау режимы, түбәндәге адрес буенча: Баулы муниципаль районы, Кызылъяр авылы, Тынычлык урамы, 9 йорт, эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 8.30 - 11.30 һәм 13.30 - 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2024 елның 5 декабреннән 18 декабрьгә кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга язма рәвештә түбәндәге адрес буенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб;

- Bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба - гавами тыңлауларны оештыручы) билгеләргә.

7. Гавами тыңлаулар оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру башлану турында хәбәр итүне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Кызылъяр

авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында www.Bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7.3. Экспозицияләрне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Кызылъяр авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 5 декабренннән 18 декабренә кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы — И.И. Гозәеров